| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>АЛЕКСАНДРОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>АЛЕКСАНДРОВКА<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Александровка авылы

16 декабря 2019 г. № 122

Төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен Александровка авыл җирлеге бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.5 статьясы нигезендә Александровка авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Александровка авыл җирлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар Баулы муниципаль районы бюджетына төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен бирелә (алга таба – башка бюджетара трансфертлар). Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары Баулы муниципаль районы Александровка авыл җирлеге башкарма комитетының норматив-хокукый актлары белән (алга таба-авыл җирлеге башкарма комитеты) билгеләнә.

2. Башка бюджетара трансфертлар шушы максатларга Александровка авыл җирлеге Советының «тиешле финанс елына һәм план чорына» Александровка авыл җирлеге бюджеты турында» гы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен баш бүлүче-авыл җирлеге башкарма комитеты.

4. Баулы муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертларны бүлү Александровка авыл җирлеге Советының «тиешле финанс елына һәм план чорына Александровка авыл җирлеге бюджеты турында» гы карары белән раслана.

5. Башка бюджетара трансфертларның максатлары һәм тәртибе авыл җирлеге башкарма комитеты һәм район башкарма комитеты арасында төзелгән килешүләр белән билгеләнә.

6. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:

а) башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

б) башка бюджетара трансфертларны бирү һәм тоту шартлары;

в) башка бюджетара трансфертлар бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) башка бюджетара трансфертларны күчерү графигы;

д) башка бюджетара трансфертларны бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшереп тору тәртибе;

е) финанс тәэминаты чыганагы башка бюджетара трансфертлар булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе.

7. Килешү проектын әзерләү авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

8. Килешү проекты авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан район башкарма комитетына җибәрелә.

9. Килешү авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе һәм район башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан имзалана.

10. Район бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертларның күләме, муниципаль берәмлекне сайлап алу критерийлары һәм шартлары авыл җирлеге Башкарма комитетының норматив-хокукый актында билгеләнә.

11. Башка бюджетара трансфертлар Баулы муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен килешүдә билгеләнгән срокларда ачылган территориаль органнары

счетларына күчерелә.

12. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Александровка авыл җирлеге бюджеты керемenә Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә күчерелергә тиеш.

13. Бирелгән елдан соң киләсе елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калганы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә, Александровка авыл җирлеге бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

14. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын закон нигезендә авыл җирлеге башкарма комитеты һәм районның финанс-бюджет палатасы контрольдә тота.

Александровка авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе В.И. Уварова